ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» ноябрь 2019 ел. № 446

2019 елда күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь төзекләндерүне тәмамлау нәтиҗәләре буенча башкарылган эшләрне кабул итү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 46 статьясына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» 31.12.2013 ел, № 1146 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «2019 елда күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау турында» 2018 елның 4 октябрендәге 442 номерлы карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы, Әгерҗе ш., М. Горький ур., 6 йорт адресы буенча урнашкан күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь төзекләндерүне тәмамлау нәтиҗәләре буенча, «Твой дом» төзелеш компаниясе ЖЧҖ подрядчысы тарафыннан башкарылган эшләрне кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 24.06.2009 ел, №82-р күрсәтмәсе белән билгеләнгән кабул итү комиссиясенә күпфатирлы йортны капиталь төзекләндерү төгәлләнгән йортны кабул итү акты буенча башкарылган эшләрне кабул итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Шамсутдиновка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.С. Авдеев**